СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №111, (7440) | 17 сентябрь, 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

Беренче планда

«Россия» колхозында шикәр чөгендере плантациясе 245 гектар мәйдан били. Аны биредә оештырылган механикалаштырылган дүрт звено җыя. Иртәдән төнгә кадәрле кырда эш кайнап тора, механизаторлар чөгендер алу өчен кояшлы һәр сәгатьне белеп файдаланырга тырышалар. Биредә хуҗалыкның иң яхшы механизаторлары Владимир Петрович Мандрейкин, Николай Иванович Перепелкин КС-6 комбайннарында эшли. Яфрак урдыру комбайнында Владимир Иванович Наумов үз вазифасын сокланырлык итеп үти. Шундый ук икенче комбайнда Анатолий Степанович Терентьев эшли. Казып алган чөгендерне бортларга куялар. Чөгендерне чистартуда хәленнән килгән һәр кеше эшли; пенсионерлар да актив катнашалар. Мәктәп укучылары һәм башка учреждение работниклары да бу эштән читтә калмыйлар.

А. КАДЯШЕВ.

Нормасын арттырып үти

Эшчән, тырыш, авыл хезмәтенә ябырылып яткан бертуган Казаковлар нәселеннән ул. Агалары Юрий һәм Валерий кебек үк техникага хирыс, җиргә гашыйк Владимир. Ул Т-150 тракторында эшли. Быел хуҗалык 720 гектарда уҗым культуралары чәчсә, ул мәйданның күбесен Владимир әзерләде. Хәзер ул туңга сөрү белән мәшгуль, нормасын һәрчак арттырып үти, сыйфатлы эшли.

Шунысын да әйтергә кирәк: Казаковларга авылда хөрмәт тә хезмәтләренә карап—зур, хәзер хуҗалык алар өчен 2 квартиралы йорт сала.

Билгеле инде, кунак ашы кара-каршы дигәндәй Казаковлар сыртны җиргә тидермәсләр. Хуҗалык үзләренә күрсәткән яхшылыкны тырыш эшләре белән аклыйлар.

РӘСЕМДӘ: «Заря» колхозы механизаторы В. А. Казаков.

Сизелерлек өлеш кертәләр

Аксумла авыл Советы территориясендә яшәүчеләрнең күбесе, ягъни 199 хуҗалык сыер тота. Аларның барысы да дип әйтерлек хуҗалыктан арткан продуктларын дәүләткә сатып бирүдә катнашалар.

Быелның 8 аенда дәүләткә 411 центнер сөт сатылды. Сатылган сөт өчен авыл халкына бер килограммы 6 сумнан акча түләнә. Ел башыннан халык белән бу темага әңгәмә уздырылды. Колхоз аларны катнаш азык, түпас азыклар белән тәэмин итә.

Сөт җыючылар Александр Николаевич Игнатьев, Петр Егорович Демьянов, Мансур Шәйдуллович Галимов вазифаларын намус белән башкаралар. Сөт җыючылар транспорт белән, башка кирәк-ярак белән тәэмин ителгән. Әнә шулай индивидуаль сектор илнең азык-төлек ресурсларын тулыландыруга сизелерлек өлеш кертә.

Г. МОРАТОВА.

• *Фермаң кышка әзерме?*

Мактанырлык урын юк

Рәфыйк Сафин, Хәбибулла Кәлимуллин, Әмирулла Рәхмәтуллин һәм Мифтахетдин Морзаханов составындагы звено савым сыерлар өчен сменалы профилакторий хәзерләү белән мәшгуль бу көннәрдә. Башкарасы эшләр күп әле. 5 бокс хәзерләп куясы, буаз сыерларны урнаштыру өчен рәтне тәртипкә китерәсе. Эштә тоткарлыклар килеп чыкмаган очракта да сентябрь азагына кадәр сузылачак әле.

—Тулаем алганда, ремонт эше канәгатьләнерлек бара,—ди колхозның баш зоотехнигы Исламгәрәй Миннекәев. —Фермаларны кышка хәзерләү буенча колхозчылардан торган ике звено, бер ялланган бригада эшли.

Соңгылары, безнеңчә әйтсәк, шабашниклар бригадасы сыерлар өчен яңа абзар кору белән шөгыльләнә. Аның кайчан өлгерәсен төгәл әйтүе кыен, корпус өлгереп килсә дә, эчке монтаж эшләренә керешмәгәннәр дә.

Хәер, анысы яңа объект. Иске, бүгеннән маллар кабул итәсе объектларда да кышка хәзерлек тулы төгәлләнмәгән әле. Фәһимә һәм Гомәр Мостафиннар, Зәйнәп Кәлимуллина эшләгән бозаулату бүлеге дә әзерләр рәтендә. Әмма тәрәзә пыялалары урынына пленка гына куйганнар.

Мотыйгулла Сәгыйров улы Хасибулла белән эшләүче абзарда да шул ук кимчелек. Тәрәзәләрдән җил уйный. Һәм башка каралтыларда да шулай. Дөрес, әйтүләренчә, колхоз ике контейнер пыяла сатып алган инде, ул андый тишекләрне каплау өчен җитәрлек. Аны тизрәк кайтартасы һәм куясы бар.

Сарыклар абзарлары күп эш таләп итми торган каралтылар рәтенә керә. Әмма вак-төяк ремонт шактый җыела.

Сыерларга бер абзар төзелә генә әле, икенчесенә капиталь ремонт үткәрәсе. Ә малларны кышкы абзарларга кайтаруга вакыт күп калмады,ашыгырга кирәк. Ташлатканнан терлекләр асрала торганында да бетонлау эшләре шактый.

Дуңгызлар асрала торган биналар да осталар кулы тигәнне көтә: кайсын агартасы, кайсын төзәтәсе, 40 баш төп ана дуңгызга исәпләнгән бинада транспортер куясы.

—Аны «Октябрьскагропроммехмонтаж» көйләүчеләре куярга тиеш, —дип аңлатма бирә ферма мөдире Фәнил Мингалимов.—Шуны өч айдан бирле көтәбез, тик килгәннәре юк әле. Алар моннан тыш котельныйны көйләү эшен дә башкарырга тиешләр.

Азык цехында да аны эшкәртеп бирү өчен күп нәрсә башкарасы бар. Терлекчелек буенча механик авырып китү сәбәпле ул тоткарлана.

Ләкин вакыт көтми. Сентябрьдә маллар тулысынча көтүдән кайта. Алар кайтканчы башкарырга тиешлесен үтәп өлгерү кирәк. Халык телендә, җылы абзар—ярты азык, диләр бит. Шушы хакыйкатьне истән чыгарырга ярамый.

Һәм тагын бер моментка тукталып үтми мөмкин түгел.Хәзер күп колхозда фермада хезмәт куючыларга тиешле шартлар тудыралар: кышкы чорда ашханәләр, саупалар эшли. Муса Җәлил исемендәге колхозда бу мәсьәлә дә хәл ителмәгән: башлаганнар да ярты юлда тукталып калганнар. Шуңа бу тармакта, йон сатудан кала, мактанырлык уңышлары да юк.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

• Безнең рейд

Вак-төякләргә урын булмасын

Районда икенче урак—чөгендер алу башланды. Безнең рейд бригадасы шикәр заводында булып, чимал кабул итү, аны озату, урнаштыру, эшкәртүнең ничек оештырылуы белән кызыксынды.

Чөгендер алу сезоны колхоз-совхозлар өчен икенче урак булса, Норлат шикәр заводы өчен төп «урак өсте»—иң кызу эш чоры. Шуңа да завод коллективы әлеге сезонга һәр елны зур әзерлек белән килә, басулардан җыелган чималны сыйфатлы продукция итү өчен күп көч куя. Быел завод өчен әлеге сезон бераз соңрак—чимал кабул итү 7 нче, аны эшкәртә башлау 10 нчы сентябрьдән башланды. Ел үзенчәлекләреннән чыгып, районда чөгендер алу һәм аны заводка озату аерым график нигезендә корылды. Инде менә чимал ташу 1 атна бара, шуңа аның беренче нәтиҗәләрен дә күрсәтергә мөмкин.

Тулаем алганда, заводның сезонга әйбәт кенә әзерләнгәнлеген билгеләп үтәргә кирәк. Быел завод эчендә байтак үзгәрешләр булды, аның тәүлеклек эшләп чыгару куәте үстерелде. Кагат кыры читендәге браковая—чөгендерне бумнарга билгеләп, үлчәүгә озату бинасы да быелга төзеп файдалануга бирелгән. Аның төп хуҗасы — браковщица Раиса Григорьевна Губанова яңа бинаның бик уңайлы булуын әйтеп алды. Әмма чимал озатучыларга беренче канәгатьсезлек сүзләренә дә шушында юлыктык. Иң элек—чималны китерү вакыты. Завод аны иртәнге 6дан кабул итә, сезон башланыр алдыннан үткәрелгән киңәшмәдә. якын хуҗалыклар җитәкчеләре хәтта аны сәгать 5 тән үк эшләтергә кирәк дип тә тәкъдим керткәннәр иде. Завод, кирәк була калса, аны да эшләячәк. Әмма аннан ни файда булыр икән—иртәнге 6га төркем-төркем машиналар көтеп тора дип уйлыйсызмы? Юк, кызганычка каршы, алай түгел шул. Без булган 15 сентябрьне генә алыйк. Аксубай районының Ленин исемендәге колхозыннан машина иртәнге сәгать 6га килеп җиткәндә, безнең Норлатка терәлеп торган «Рассвет»тан 7 сәгать 30 минутта, Кузнецов исемендәге колхоздан 7 сәгать 45 минутта, «Кондырча»дан 8 сәгать 40 минутта, хуҗалыкара берләшмәдән 8дә, Мичурин исемендәге колхоздан 8 сәгать 10 минутта гына килеп ирештеләр.

Мондый акрын селкенүне шоферлар үзләре дә сөймиләр, әлбәттә. «Заветы Ильича» колхозында командировкада эшләүче Н. Сөнгатуллин хуҗалыкта иртән төяүнең соң башлануын, кичен 5тән үк тукталуын канәгатьсезлек белән сөйләп алды. Нидисәң дә, шушындый көннәрдә 5тән эш туктату аларның да кесәсенә суга бит. Дөрес, чөгендерне массакүләм ташу тотылган дип булмый: әлегә көнгә 2—3 мең тонна чимал гына китерелә, массовый чимал ташу башлангач, ул 8әр мең тоннага җитәчәк. Әле аз озатылганда, аны карап озатырга, товар-транспорт накладноена дөрес тутырырга мөмкинлек тагы да зуррак. Әмма беренче көннәрдә үк чөгендер игү звеносы җитәкчеләренең аны тутыруга игътибарсызлыгы үзен сиздерә. Раиса Григорьевна шул сәбәптән генә беренче накладнойны кире борды, тутырып бетерергә киңәш бирде. Ә бу аның вазифасына керми, төп эшенә тоткарлык ясый. Икенче яктан, ул аңа игътибар бирмәсә дә, завод берни югалтмый, киресенчә, ота гына. Ә хуҗалыклар югалталар, һәм шактый. Эш шунда: завод хуҗалыкларга йөк ташуда транспорт чыгымнары өчен тәүлегенә 3 меңнән 11 меңгә кадәр акча түли. Әгәр накладнойда машинаның каян булуы язылмый икән, завод аңа түләмәскә хаклы. Еш кына машина номеры, шофер фамилиясе күрсәтелми. Бу очракта шофер үзе дә контроль алып барырга тиеш, чөнки завод чимал ташыган өчен 1 тонна-километрга 6 грамм исәбеннән тиешле шикәр комын кемгә бирергә икән дип эзләп йөрмәячәк. Машина маркасын билгеләү дә мөһим, чөнки аларның һәрберсенә түләү тарифы төрле, үзбушаткычларга аеруча югары түләнә. Без булган көнне генә дә Кузнецов исемендәге, «Кондырча», «Россия» колхозларыннан, хуҗалыкара берләшмәдән шулай тутырып бетерелмәгән накладнойлар белән килгәннәр иде.

Чимал төягән машиналар аннан үлчәүгә юнәләләр. Биредә 30 ар һәм 60 ар тонналы үлчәүләр эшли. Әмма быел 60 тонналы үлчәүнең берсе еш ватылып җәфалый. «Шикәр чөгендерен контроль үлчәү учеты журналы»ннан күренгәнчә, 8, 9, 11, 14 сентябрь көнне дөрес күрсәтмәү сәбәпле (аер-

(Бары. Ахыры 2 биттә).

Балтач—Норлат: дуслык, тәҗрибә визиты

Район укытучыларының традицион август киңәшмәсеннән соң икенче көнне бер төркем мәгариф работниклары—мәктәп директорлары, авыл балалар бакчалары, башлангыч мәктәпләр җитәкчеләре, РОНО, яшь туристлар станциясе хезмәткәрләре —барлыгы 21 кеше Балтач районына юл тотты. Бу визит берничә максатны күздә тотты. Шуларның икесе — авыл башлангыч мәктәбе һәм балалар бакчасы эш тәҗрибәсе белән танышу булса, мәктәп яңы тәҗрибә участоклары, музейлар эш практикасын өйрәнү дә планлаштырылган иде.

Тәҗрибә уртаклашу юнәлешләрен район халык мәгарифе бүлеге мөдире Н. Х. Абдуллин билгеләде. Май аенда Балтач районы базасында республика халык мәгарифе бүлекләре мөдирләре киңәшмәсеннән кайткач, ул әлеге район укытучыларының күркәм башлангычлары, уңышлары турында исе китеп сөйләгән иде. Шуңа да анда зур кызыксыну белән җыендык. Ни дисәң дә, йөз тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр күрүең яхшырак.

...Һәм менә без инде Балтач җирендә. Җәй дәвамында бирегә тәҗрибә өйрәнүгә килүчеләрнең уночынчысы булсак та, безне ачык йөз белән каршы алдылар, «Романтик» пионерлагерена урнаштырдылар. Нарат урманы уйсулыгы кырыендагы бу лагерьга килгән кунакларны, безнең ише тәҗрибә өйрәнүчеләрне урнаштыралар икән.

Шул ук көнне Балтач авылында йөрдек: нараттан төзелгән һәм муллык, байлык билгесен чагылдыручы сары төскә буялган йортлар, ачык йөзле, кунакчыл халкы белән якыннан таныштык.

Икенче көнебез тулысынча тәҗрибә уртаклашуга багышланган иде.

Барысы да заманча

Районда бер авыл профессиональ- техник училищесы бар. 19 урта, 1 тулы булмаган урта, 32 башлангыч мәктәп эшли.

Балтачта яшәүче төп халык—татарлар. Шуңа балаларга белем бирү нигездә татар телендә алып барыла. Дөрес, ике удмурт мәктәбе (барлык халыкның 11 проценты удмуртлар) дә бар. Мәктәпләрдә барлыгы 5 мең бала укый. Белем бирү учреждениеләрендә 1800 педагог эшли. Иң элек шуны әйтергә кирәк: педагоглар составы сыйфат ягыннан елдан-ел яхшыра. РОНО мөдире Х. Х. Хәсәнов билгеләгәнчә, соңгы 8 елда 87 укытучы пенсиягә киткән. Шул ук чорда район педагоглары армиясе 258 кешегә тулыланган. Барысы да яшьләр, барысы да махсус белемле, барысы да Балтач җирендә үскән кешеләр. Бүгенге көндә мәктәпләрдә укытучы урынына вакансия булмау да шуның нәтиҗәсе. Салавыч урта мәктәбе директоры Л. Х. Закирова әйткәнчә, байтак мәктәпләр укытучыларны конкурс нигезендә эшкә алалар икән (!).

Алда әйтелгәнчә, районда мәктәпләр саны ике дистәләп. Шуларның 16 сы республика халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнашкан. Мәктәпләрнең һәркайсында кече фермалар бар. Әмма балтачлылар анда мәктәп балалары эшләтүгә тамырдан каршы.

Шунысы игътибарга лаек, район мәктәпләре тулысынча компьютерлаштырылган. Быел исә һәр башлангыч мәктәпне дә берәр компьютер белән җиһазландыру планлаштырыла.

Боларның һәркайсы, һәм бүген һәр мәктәпнең уңайлыклы, типовой бинада урнашуы база хуҗалыклары белән элемтәнең нык булуы турында сөйли. **Карадуган мәктәбенә**, мәсәлән, Карадуган мебель фабрикасы, «Алга», Калинин исемендәге колхозлар шефлык итәләр. Шефлар кадрлар хәзерләү үзәге булган мәктәпкә бик җитди карыйлар: мәктәп бакчаларын ашлау, ашханәне азык-төлек белән тәэмин итү, кадрлар мәсьәләсе—барысы да алар өстендә. Бу күп җирдә шулай куелган. Быел район мәктәпләрендә 16 автомашина, 24 көпчәкле һәм чылбырлы трактор, 10 комбайн булуы да шул турыда сөйләмимени?

Хәйран икән

Районда 43 балалар бакчасы эшли. Балалар бакчасына йөрүчеләр саны 3 меңләп. Бакча хезмәткәрләренең 92 проценты—махсус белемле.

Шәхсән минем әлегә кадәр мондый балалар бакчалары күргәнем юк иде. Менә без Карадуган балалар бакчасында. Калкулыкка урнашкан ике катлы бу бина авылга ямь биреп тора. Бакчасына керүгә үк ГАИ постына юлыгасың. Пост будкасы да, светофор да, юллар бүленеше дә...—барысы да бар дигән. Бакчаның чәчәк участоклары түбән читән белән тотып алынган. Алсу, комач кызыл розалар, күперенгән флокслар, георгиннар һәм сирәк очрый торган сортлы чәчәкләр. Шунда ук фонтан, бассейн, спорт, уен мәйданчыклары. Ә калын нарат бүрәнәләрдән салынган әкияти йортта нәрсә икән? Җеен балалар уйнап туйгач, шунда ял итәргә керәләр икән. Искиткеч матур ул. Уенчыкларның да җаның теләгәнен сайлап ал.

Балалар бакчасының эчке өлеше тагын да матуррак. Үзеңне әкият дөньясындагыдай хис итәсең. Шулкадәр зәвык, югары культура, уңайлык... Сөйләп бетерә торган түгел. Биредә ике пианино бар, Тукай почмагы җиһазландырылган, аскы катта хәтта музей да бар. Ул спортзал! Ул гөлләр, ул паннолар, мәктәпләр көнләшерлек бит.

Бакча мөдире белән сөйләшәбез.

—Барысын да үз кулларыбыз белән ясыйбыз. Оста ир-атларыбыз да бар безнең. Аннан эшебезне, балаларыбызны яратабыз. Ә бу күп нәрсә йөкли,—ди ул.

Әйе, үзләре дә тырыша, мәктәп тә ярдәмгә килә, база хуҗалыклары Калинин исемендәге «Алга» колхозлары, Карадуган мебель фабрикасы балалар турында кайгыртмыйча яшәүне күз алдына да китерә алмыйлар.

Без бу көнне Салавыч балалар бакчасында, Ульисьял мәктәп-балалар бакчасы учреждениесендә дә булдык. Анда да мәктәпкәчә яшьтәге балаларга булган игътибар хәйран калырлык. Районда ник бер яраклаштырылган балалар бакчасы булсын, барысы да типовой. Ә кешеләре, биредә эшләүчеләре нинди аларның. Кояштай йөзләре, тәмле телләре... Ә кулларыннан, кем әйтмешли, гөл тама.

Теория+практика=эксперимент

Балаларга политехник белем бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру, мәктәптә бөтен укыту-тәрбия процессының сыйфатын күтәрү мәктәп яңы тәҗрибә участогына мөнәсәбәт белән турыдан-туры бәйле. Шуны истә тотыптыр инде, балтачлыларның моңа игътибары бик зур. Райондагы барлык мәктәпләрдә дә гомуми мәйданы 39 гектарга тигез шундый участоклар, болардан тыш, һәркайсында җиләк-җимеш бакчасы, 15 питомник булуы үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Әлеге участоклар биология буенча практик эшләр үтәү, тарату материалы, күргәзмә әсбаплар хәзерләүгә хезмәт итсә, яшелчә, җиләк-җимешләр мәктәп ашханәсен баетуга китә. Әнә, Салавыч мәктәбе питомнигында укучылар алманың беренче һәм икееллык үсентеләрен үстерәләр. Үзләре үк аларга ялгау да ясыйлар икән. Узган ел биредә 290 төп кара, 80 төп кызыл карлыган, 64 төп крыжовник үсентеләре үстерелгән. Шуның бер өлешен үз участокларына утыртканнар, калганын күрше мәктәпләргә таратканнар.

Карадуган урта мәктәбе дә бу яктан иң үрнәкләрдән санала. Уку-тәҗрибә участогының декоратив чәчәкләр бүлеге иртә яздан беренче карга кадәр чәчәккә күмелеп утыра. Моңа үсемлекләрне чәчәк ату сроклары буенча дөрес сайлау нәтиҗәсендә ирешкәннәр.

Кыскасы, бу турыда бик озаклап сөйләп булыр иде. Әмма дендрарий турында әйтми калу мөмкин түгел. Карадуганлылар аны нигездә үзагач-куак (древесно-кустарниковая) флорасының төр составын өйрәнү максатында булдырганнар. Биредә төрле агачларның бай коллекциясе тупланган. Ә тулаем район мәктәпләрендә 11 дендрарий бар. Мәктәп укучылары ел дәвамында үстергән җиләк-җимеш, яшелчәдән өзелми. Бу турыда сөйләгәндә, мәктәпләрдә 16 теплица булуын, анда елның-елында мул уңыш үстерелүен дә әйтми мөмкин түгел.

Тагын бер нәрсә. Балтач педагоглары үз укучыларына мөстәкыйль рәвештә тәҗрибә үткәрүгә дә елдан-ел киңрәк мөмкинлекләр ачалар. Узган ел, мәсәлән, Кече Лызи урта мәктәбе укучылары кишер белән эксперимент үткәргәннәр. «Кишер үсентеләрен сирәкләү срокларының уңдырышлылыкка йогынтысы» дип аталган тәҗрибәнең нәтиҗәсе исә һәр гектардан 400 центнер кишер җыеп алырга мөмкинлек биргән. Сәмәел мәктәбе укучылары «Бәрәңгенең иртә сортларын өйрәнү» темасы өстендә эшләсәләр, Карадуган мәктәбендә Казан авыл хуҗалыгы институты заданиесе буенча «Орлыкны серкәләр белән дымландырып чәчүнең төрле сорт кишернең үсеше һәм уңдырышлылыгына тәэсире» темасы өстендә фәнни-тәҗрибә үткәргәннәр. Салавыч мәктәбе укучылары исә бакыр кертеп минераль ашламалар куллануның бәрәңгенең уңдырышлылыгын күтәрүен ачыклаганнар. Шул ук мәктәптә «Память Мичурина» сортлы кара карлыган белән тәҗрибә үткәргәннәр. Һәм, әйтергә кирәк, барлык эзләнү, тәҗрибәләр өйрәнелә, гомумиләштерелә, уңай тәҗрибә киң таратыла.

Бурыннар күпере

Балтач районында дүрт музей бар.

Болары—паспортлаштырылган, бөтен таләпләргә җавап бирә торганнары. Ә туган якны өйрәнү, этнография музейлары, почмаклар һәр мәктәп, хәтта балалар бакчаларында да бар. Биредә музейларның балалар тәрбияләүдә мөһим күргәзмә мисал булуын тирәнтен аңлыйлар. Карадуган мәктәбе каршындагы музейны карадык. Ул 8 бүлмәдән торган иске мәктәп бинасына урнашкан һәм мәшһүр татар шагыйре Муса Җәлилнең тормыш юлы, иҗатына багышлана. Иркен, экспозицияләргә бай бу музей Республика музеенннан һич ким түгел. Шуңа да аны быел гомумиләштерелгән дәүләт музееның филиалы итмәкчеләр икән.

Ә менә Чепья авылындагы музей берничә ел инде дәүләт музее филиалы булып тора. Анда әлеге регионның үткәне, Чепья авылы тарихы, районның рус революциясе, Бөек Ватан сугышы чорындагы эшчәнлеге буенча бүлекләр бар. Музей 1965 елда, Бөек Ватан сугышында җиңүнең 20 еллыгы уңаеннан ачылган. Музей 6 квадрат метрдан башланган. Бер елдан соң, яңа мәктәп төзелгәч, искесе тулысынча музей карамагына тапшырыла. Берничә ел эчендә музей киңәйтелә. Бүгенге көндә анда экспонатлар саны 6 меңнән артып киткән. Төп эшне музей советы җитәкли. Тарихи һәйкәлләрне саклау, туган якны өйрәнү буенча зур эшләр башкарылган.

1987—1988 елларда район җитәкчеләренең турыдан-туры зур күләмле ярдәме нәтиҗәсендә музейда реставрация эшләре үткәрелгән. Аны Ленинград рәссам-бизәүчеләре башкарган. Бүгенге көндә «Халыклар дуслыгы» исемен йөртүче Чепья музее Татарстан Республикасы берләштерелгән Дәүләт музее филиалы итеп үзгәртелде.

Кунак ашы—кара-карш

...Ул көнне районны
аркылыга-буйга үттек
без. Районда укытучы
мәктәпнең җәмгыятьтә
тоткан урыны югары бу
луына ышандык. Арал
шу барышында укытучы
ларны иҗади эшләүг
этәрүче нәтиҗәле стиму
ларның да шактый булу
аңлашылды. Һәм, и
мөһиме, алар өстән райо
җитәкчелеге кайгыртуы
нан килә икән. Аларны
берничәсен күрсәтеп ү
мәкче булабыз. Ел сә
районда укытучылар өч
сабантуй үткәрелә. Ан
уку елы тәмамлангач, а
йомгак ясау, иҗади э
ләүче коллективлар, п
дагогларны билгеләү, һ
әлбәттә инде, күңел ач
очен оештырыла. Бу
раны үткәрүгә бүленә то
ган акча средстволар
ның байтак өлеше рай
бюджетыннан керә. Анн
ры халык депутатлары
ның Балтач район Сов
ты президиумы карар
нигезендә халык мәгар
фе работникларына, те
ник работникларга, м
тәп-бакчаларда эшләп
еклы ялга киткән пенси
нерларга материаль ярд
күрсәтүне район җита
челегенең педагоглар т
рында кайгыртуы дими
ничек бәялисең?
Яисә икенче бер мисал
Укытучылар өчен мәкт
каршында ук итлек м
суела. Каян, нинди дис
ме? Алда телгә алынг
кече фермада үстерелг
терлек, әлбәттә. Колх
совхозлар белән килеш
нигезендә ул педагогла
га ярты бәясенә генә р
лизацияләнә. Билгеле
де, монда да район ж
тәкчелегенең «кулы у
ный». Аннары, бәйрәм
нәргә укытучылар өч
дефицит товарлар, дәүл
бәясенә азык-төлек п
дуктлары һәм башкал
ны бирү дә биредә гаж
хәл түгел. Укытучыла
ны торак белән тәэмин
дә тиешле дәрәҗәгә
елган. Гомумән, район
фатир алуда укытучыл
иң зур льготалардан ф
даланалар. Һәр хуҗал
һәм РОНО арасында
«50х50» килешүе ни
зендә һәр төзелгән
йортның берсе мәгари
работникларары карама
на тапшырыла. Ә ала
ягулык бирүне тотк
лауны биредә зур ж
ять саныйлар. Алай г
да түгел, районда һ
укытучы гаиләсен ши
комы белән тәэмин
дә каралган. Бусы
база хуҗалыгы вазифа
Хәер, укытучы, мәкт
нең дәрәҗәсен күтәрү

(Башы. Ахыры 3 битт

Вак-тояклэргэ урын булмасын

(Ахыры. Башы 1 биттә).

ма 200—260 килограмм) әлеге үлчәү ремонтка туктатыла. Дөрес, аның эше өчен җаваплы А. Н. Исаев көне буе биредә, әмма даими ватылып торуы массакүләм хәзерләүләр башлангач эштә тоткарлык тудырырга мөмкин. Шуңлыктан завод белгечләренә үлчәү хуҗалыгы эшчәнлегенә контрольне көчәйтергә кирәк.

Чимал лабораториясендә икенче рюпро линиясе дә эшкә җибәрелмәгән килеш. Дөрес, әлегә беренче линия әйбәт эшли, тоткарлыклар юк. Чималның шикәрлелеген билгеләүче Венера һәм Игорь Яковлевлар шатлык белән хәбәр итәләр: шикәрлелек узган ел белән чагыштырганда югары—14—16 процентка кадәр бара, контроль тикшерүләр дә шуны күрсәтә. Лаборатория мөдире Л. Мөхәммәтҗанова да әлегә чимал сыйфатының әйбәт булуын ассызыклый. 15 сентябрьгә, мәсәлән, шикәрлелек 15,1 процент, пычраклылык 7,6 процент тәшкил итсә, узган елның шул чорында ул шул тәртиптә 14 һәм 12,7 процент булган. Соңгысы пычраклылык дәрәҗәсе ягыннан шулай да аерым хуҗалыкларга кисәтү ясамый мөмкин түгел. Лаборатория хезмәткәрләре бертавыштан әйтәләр: иң чиста чөгендер «Заветы Ильича» колхозыннан килә, анда пычраклылык 4—6 процент чамасы. Ә «Россия», «Большевик» колхозларында ул бик югары, соңгысында хәтта 13 процентка кадәр җитә. 14 сентябрь көнне, мәсәлән, «Большевик» колхозы шул сәбәптән генә зачет вакытында 27 тонна чималын югалтты. «Восход» колхозы һәм хуҗалыкара берләшмә исә чөгендердә яшел күп калудан зур зыян күрәләр. «Россия», XXI партсъезд исемендәге колхозлар чимал белән бергә... эре-эре ташлар да төяп җибәрәләр хәтта. Әмма ни гаҗәп—чөгендернең сыйфаты турында мәсьәлә белән кызыксынучы белгечләр, хуҗалык җитәкчеләре бармак белән генә санарлык. Ни сәбәптәндер алар завод билгеләгән анализ белән килешеп, эшне җайга салу турында уйламыйлар да. Чимал тапшыру чорында лабораториядә хуҗалык агрономнарының дежурлык графигы да бөтенләй үтәлми. Ә бит колхоз-совхоз белгечләре бер генә көн чимал кабул итүгә контроль булдырсалар да төрле шикләнүләргә урын калмас, һәр ике як өчен дә файдага гына булыр иде.

Әлегә кагат кырында 6—7 бум эшләп тора. Быел К-700, Т-150 маркалы тракторларны бушату өчен махсус бум җайланды. Элек аларны заводта теләмичә генә кабул итсәләр, хәзер бумда чистарту, кагатка сою көйләнгәнлектән, әлеге марка техниканы да чимал ташуда иркенләп кулланырга була. Тик шунысы да бар: завод атнадан артык чимал кабул итсә дә буртларны известь белән эшкәртү башкарылмаган әле. Микробиолог Л. Дубовицкая аны 1—2 көн эчендә җайга салырга вәгъдә бирде бирүен (кешесе сөйләшенгән, килешенгән), әмма аны беренче көннәрдә үк эшләү зарур ләбаса. Шуның өстенә завод әле тулы куәтенә чыга алмаган башлангыч чорда—бигрәк тә. Бусы, дөрес, шулай ук ритмга керү алдыннан инде. Чөнки әлегәчә сырец белән эшләгәнлектән, коллективта заводны шикәр чөгендеренә күчерергә әзерләнү өчен ара бик тыгыз булды. Сок чиртарту әйбәт бара, су басулар булмады, соңгы Вульфсон (әлегә анда В. Т. Имуков) сменасы 560 тонна чөгендерне тапаткан —димәк, эш тәртипкә салыначак дип уйларга әйбәт нигез бу. Заводның көйле эшли башлавы колхоз-совхозларның массовый чимал ташуын да таләп итәчәк. Хәер, монысының вакыты җитеп килүен хуҗалыклар үзләре үк аңлыйлар. Шуңа да аңа югарыда телгә алынган, беренче карашка вак тоелган, әмма аңлашылмаучылык, үзара үпкә һәм ахыр чиктә югалтулар китереп чыгарырга ихтимал кимчелекләрне бетереп керешергә иде.

Н. ФОМИН,
авыл хуҗалыгы продуктларын әзерләү һәм сыйфат буенча баш дәүләт инспекторы.

С. ХӘЙРУЛЛИНА,
газета корреспонденты.

Газеталар яшәргә тиеш

Газета һәм журналларга быелгы язылу чоры матбугат сүзенең, хәбәрдарлыкның көннән-көн кыйбатлана баруын күрсәтә.

Гаять зур инфляция шартларында Татарстан журналистларына ничек үз-үзләрен саклап калырга? Татарстан яңалыклар агентлыгы хәбәрчесенең шушы һәм башка сорауларына республиканың «Информация һәм матбугат» министры Ш. Ш. ХАММАТОВ җавап бирә.

ХӘБӘРЧЕ: Шамил Шәмсиевич, урыннардан алынган мәгълүматларга караганда, вакытлы матбугатка билгеләнгән югары бәяләр күп язылучыларны авыр хәлгә куя. Сезнең карашыгызга, нинди басмалар «яшәүдән туктарга» мөмкин?

Ш. Х. Базар мөнәсәбәтләре һәр басманы үз урынына куяр. Теге яки бу газета-журналның тиражы турында хәзергә сөйләү кыен: бүген ул кечкенә булса, иртәгә үсәргә мөмкин. Мәсәлән, «Вечерняя Казань» газетасы 1979 елда бары 5 мең данә тираж белән чыга башлаган иде. Ә чагыштырмача яшь газеталарның, әйтик, «Татарстан хәбәрләре», «Известия Татарстана», «Шәһри Казан» һәм «Казанские ведомости» газеталарының башлангыч чордагы тиражлары шактый зуррак булды. Әмма бу хәл тынычланырга хокук бирми, укучылары күп булмаса, теләсә кайсы газета яшәүдән туктый...

ХӘБӘРЧЕ: Безнең республикада шәһәр һәм район газеталарына ябылу куркынычы яныймы?

Ш. Х. Киресенчә, финанс һәм экономика шартларының катлаулы булуына карамастан, Татарстанда аларның саны арта бара. Мәсәлән, соңгы ике елда татар телендә чыга торган алты газета ачылды. Алар Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Түбән Кама районнарында, Чаллы шәһәрендә чыгарыла башлады.

Хәзер яңа оештырылган Әтнә, Кайбыч, Теләче һәм Ютазы районнарында газеталар барлыкка килә. Дөрес, безнең министрлык күп кенә район газеталарын берләштерү мәсьәләсен куйган иде, ләкин җирле администрация моңа риза булмады, һәркем үзенең басмасы булуын тели.

ХӘБӘРЧЕ: Бу, мөгаен, район һәм шәһәр газеталарының җирле бюджет аша финанслануыннан килә торгандыр? Шулай булганда матбугат белән уртак тел табу җиңелрәк бит.

Ш. Х. Кем түли, музыкага заказны шул бирә, дигән фикер белән килешсәм дә, мин барлык җирле газеталарны да «сүз тыңлаучан» дип әйтмәс идем. Матбугатның тулы иреклелеге беркайчан да һәм беркайда да булмады. Ләкин эштә матбугат турындагы законны кулланырга өйрәнергә кирәк әле.

ХӘБӘРЧЕ: Кайбер урыннарда редакция белән типография арасында каршылыклар кыза. Аларны хәл итүдә министрлыкның роле нинди? Типографияләр бит сезнең үз улларыгыз кебек, ә редакцияләр—үги бала сыман.

Ш. Х. Әйе, типографияләргә җиһазлар безнең аша килә. Ә газета редакцияләренең үз оештыручылары бар. Ләкин без типографияләр белән редакцияләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салырга тырышабыз, газеталарны бастырып чыгару бәяләренең реаль булуына омтылабыз. Шуңа күрә, мәсәлән, Бөгелмәдә туган каршылыкларны хәл итү өчен махсус группа төзеп җибәрүебез очраклы күренеш түгел.

ХӘБӘРЧЕ: Шамил Шәмсиевич, журналистларга экономик киртәләрне элемтә эшчеләре дә сала бит...

Ш. Х. Республика басмаларына килгәндә, без элемтә органнары белән уртак тел таптык. Нәтиҗәдә—аларга язылу бәясе артык зур түгел. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан», «Советская Татария» газеталарына ярты елга 312 сум.

Районнарда мәсьәлә кыенрак хәл ителә. Анда газеталар турында аларны оештыручылар кайгыртырга тиеш: газетаны тарату өчен дотацияне җирле администрация бирә ала.

ХӘБӘРЧЕ: Сезнең министрлык күп тиражлы газеталарга нинди дә булса булышлык күрсәтәме? Казанда алар һаман ябылалар.

Ш. Х. Күп тиражлы газеталарның бүгенге һәм киләчәк хәле предприятиеләрнең хезмәт коллективларына гына бәйле. Сакланып калган басмаларга без кәгазь фонды белән ярдәм итәбез. Дөрес, республика һәм район газеталарын тулысынча тәэмин иткән кебек үк түгел.

ХӘБӘРЧЕ: Шамил Шәмсиевич, Сез бер үк вакытта министр да, Татарстанның Журналистлар берлеге идарәсе рәисе дә. Берьюлы ике урындыкта утыру кыен түгелме?

Ш. Х. Әйе, кыенрак... Бөтенесе дә—массакүләм информация чаралары хезмәткәрләре дә, берлек әгъзалары да, полиграфистлар да материаль ярдәм яки башка төрле булышлык сорыйлар бит. Журналистика ветераннарын да онытмыйбыз, алар арасыннан 115 кешегә безнең Журналистлар берлеге ай саен 200 сум биреп бара.

Иң авыр мәсьәлә— акчаны каян алырга? Иҗат Берлегенең язмышы, минем уемча, аның кече предприятиеләр исәбенә үсә алмавына, әлеге предприятиеләрнең киң нәшрият-коммерция эшчәнлегенә сәләтле булуларына бәйле. 10 сум күләмендәге еллык членлык взнослары гына безне коткара алмый инде.

Хәзер безнең Берлек каршында «Сам хозяин» газетасы чыгып килә. Татарстан яңалыклар агентлыгы (ТАН) эшли, ул җирле газеталарны һәм журналларны оператив информация белән тәэмин итә. Агентлыкка республикадан читкә чыгарга да вакыт җитте.

Күптән түгел Татарстан Министрлар Кабинеты журналистлар лотереясы уткәрү турында карар кабул итте. Анда күп кенә кыйммәтле әйберләр уйналачак.

ХӘБӘРЧЕ: Соңгы сорау. Министрлык, иҗат Берлеге һәм җирле басмалар арасында оператив төстә информация алмашу кайчан җайга салыныр?

Ш. Х. Бу—шулай ук өлгергән мәсьәлә. Экономияләнгән бюджет акчалары исәбенә республиканың эре шәһәрләрендә телефакслар кую юлы белән тиздән бу мәсьәләне хәл итәчәкбез. Бу аппаратлар белән республика газеталарының үз хәбәрчеләре дә, район журналистлары да файдалана алырлар.

Балтач—Норлат: дуслык, тәҗрибә визиты

аның бүгенге көндәге рөлен билгеләүче төп фактор да мәктәп белән бала хуҗалыгының шулай иңгә-иң куеп эшләведер, безнеңчә. Һәм, алда әйтелгәнчә үк, боларның барысы да өстән, ягъни район җитәкчелегеннән тора. Ә кунак аңы кар-каршы. Быел районда халык мәгарифенең даны еракларга яңгыраган балтачлыларның тәҗрибәсен башка районнардагы коллективлар да өйрәнәләр, аның белән тирән кызыксыналар икән һәм бүген укытучыларның иҗади эше бары тик мактауга гына лаек икән, бу аларның кайгыртуга олы җавабы.

x x x

Балтачлыларның эш тәҗрибәсен өйрәнү безгә шундый ачышлар китерде. Һәм, дөресен әйтик, урынлы кәнәшү дә тудырды. Акланырга җыенмыйбыз: безгә әле, гәрчә байтак уңай тәҗрибәбез булса да, укыту-тәрбия балаларга хезмәт тәрбиясе бирү дәрәҗәсен балтачлылар биеклегенә күтәрү өчен шактый хезмәт куясы бар. Икенче яктан ник яшерергә,— район җитәкчелеге тарафыннан мәгариф мәнфәгатьләренә игътибар, педагоглар ихтыяҗын аңлап, ярдәм итәргә омтылып карау да бездә җитеп бетми. Зур чыгымнар да таләп итмәгән бу кайгыртуны тоюның ахыр чиктә шул ук җәмгыятькә икеләтә, өчләтә игелек булып кайтуын язмадан һәркем аңлагандыр.

Без үзебез юл буе шул хакта гәпләшеп кайттык, эшебезне тагы да җанландырырга планнар кордык. Һәм үзебез кайчан бик-бик сусаган хуплау, ярдәмгә дә игътибар туды.

Р. ИБРАҺИМОВА,
район яшь туристлар станциясе директоры.



«Брянсксельмаш» заводы вакытлыча туктарга мәҗбүр булды. Эшчеләр түләүсез ялга чыгып беттеләр.

«Брянсксельмаш» төрле модификация ашлык киптерү комплекслары эшләп чыгара. Бәяләр күтәрелү сәбәпле, колхоз-совхозлар аларны сатып ала алмыйлар. Шул ук бәяләр аркасында җиһазларны фермер да ала алмый. Шуңа күрә бөтен территория реализацияләнмәгән техника белән тулы.

Завод эшчеләре бөтен кайгыларының сәбәбен чимал, ягулык, электр энергиясенә, комплектлаштыру детальләренә бәя үсүдә һәм өстәмә бәягә булган 28 процентлык налогта күрәләр.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

ШИМБӘ
19 СЕНТЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

7.00 «Чулпан».
16.20 «Ералаш» киножурналы.
16.30 «Июльдә өч көн». Чаллы шәһәре балалар слетыннан репортаж.
16.50 «Татарстан телевидениесе фондыннан». Н. Фәттах. «Кол Гали». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле.
19.00 Татарстан.
19.30 Гөлдания Хәйруллина жырлый.
19.35 Әлли-бәлли-бәү.
20.00 «Алла булу кыен». Нәфис фильм. 2 серия.

ОСТАНКИНО КАНАЛЫ

6.00, 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Яңалыклар.
7.20 Иртәнге гимнастика.
7.30 Эшлекле кешенең шимбә иртәсе.
8.30 Спорт-шанс.
9.00 «Марафон-15».
9.25 Үз-үзеңә ярдәм ит.
9.55 «Труба» радиосы.
10.25 Һөнәрләрнең тере агачы.
10.30 Кеше институты.
11.00 Ирландия очрашулары.
11.30 Мультфильм.
11.40 «Минем кадерле кешем».
13.40 Музыкаль киоск.
14.10 «Боинг легендасы». Телефильм. 1 кисәк.
15.15 «Сәясәт» студиясе.
15.55 «Әкият турында әкият». Нәфис фильм.
16.50 «Госко» акционерлык җәмгыятен тәкъдим итү.
18.50 Кызыл квадрат.
19.30 «Янутлар». Мультфильм.
19.55 Телевизион таңылык.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.40 «Кышкы чия». Нәфис фильм.
23.05 Зодиак билгесе астында. «Кыз».
00.50 «Мәхәббәтнең мәңгелек җыры». Киноконцерт.

«РОССИЯ» КАНАЛЫ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.25 Храмга юл.
8.45 Ял вакыты.
9.00 Спорт дөньясы. «Жиллет» фирмасы күзлегеннән караганда.
9.30 Манера.
10.00 «Ретро». В. Шубарин.
10.30 Америка йолдызлары.
11.00 «Плюс унбер» видеоканалы.
12.15 Ничек яшәрбез.
13.00 Пилигрим.
14.20 «Пилигрим» капитаны». Нәфис фильм.
15.50 Дуслар йорты.
16.10 Хәзерге заман сәнгате музее.
16.40 Мегаполис.
20.30 Алтын шпора.
21.00 «Ялгызлык яратучы кеше». Нәфис фильм.
22.15 Ляпсус.
23.20 «А» программасы.
00.05 Россиядә секс-индустрия.

ЯКШӘМБЕ
20 СЕНТЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

7.00 «Чулпан».
16.00 «Хыялланыр чак». Нәфис фильм.
17.25 Бездә кунакта Кытай циркы.
18.35 «Яшьлегемә кире кайтыр идем». Концерт. Тәнәфестә (19.55)—Әлли-бәлли-бәү.

ОСТАНКИНО КАНАЛЫ

7.00 Рухи көч сәгате.
8.00 «Спортлото» тиражы.
8.10 Мультфильм.
8.20 Украин кичләре.
9.00 Иртән иртүк.
9.30 Бар да мөмкин.
10.00 Иртәнге йолдыз.
11.30 «Пи» билгесе астында.
12.20 Яңа буын сайлый.
13.10 Үткән көннәр.
13.50 «Сынлы сәнгать метаморфозалары». 7, 8 серияләр.
15.20 «Сәясәт» студиясе.
15.55 Киносәяхәтчеләр клубы.
16.45 Халык көйләре.
17.00 Панорама.
17.40 Телелоция.
17.55 Уолт Дисней тәкъдим итә.
18.45 Яңалыклар.
19.05 Маринскийда променад.
20.00 Кино яңалыклары.
20.25 «Кышкы чия-2». Нәфис фильм.
22.00 Йомгаклар.
22.45 Спорт уикэнды.
23.00 Брэйн ринг.
00.50 «Париж—Мәскәү—Пекин» автораллие.

«РОССИЯ» КАНАЛЫ

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр.
8.20 Атның рәсемен кем ясар?
8.40 Мульти-пульти.
9.20 Таныш булмаган мәдәниятләр.
9.50 Ышансагыз, ышаныгыз.
10.20 Сезнең өчен, малайлар һәм кызлар.
10.30 Крестьян мәсьәләсе.
11.00 «Патшалыктагы мәкара». Мультфильм. 4 серия.
11.30 «Аты-баты».
12.00 Бумеранг.
13.00 Менеджерлар конкурсы.
14.20 У. Сароян. «Нәниләрне кыйнау». Спектакль.
15.50 Россия энциклопедиясе.
20.30 «Сары су асты көймәсе» клубы».
21.00 Голливудның классик фильмнары фестивале. «Башваткыч».
23.00 Спорт каруселе.
23.30 «Апокриф».

Объективта—һиндия



РӘСЕМДӘ: Һиндиядәге кебек үк Калькуттада да һәр җирдә—урамнарда, мәйданнарда сыерлар йөри. Бу аларда гадәти күренеш.

Һиндиядә уңыш җыеп алу вакытында традиция буенча ярминкәләр, фестивальләр үткәрелә. Аларда, кагыйдә буларак, төрле ярышлар уздырыла.

РӘСЕМДӘ: 65 яшьлек Синх 100 килограмм авырлыктагы көпчәкне җиңел күтәрә.

САМАРА ӨЛКӘСЕ. Буш вакытта нәрсә белән шөгыльләнергә? Тольятти шәһәренең балалар һәм үсмерләр иҗаты йорты каршындагы зоологик түгәрәккә йөрүче балаларның җавабы әзер: билгеле, үзләренең яраткан хайваннарын карыйлар.

Рәсемдә: ташбака Алиса иртәнге ашка кишер ашарга ярата.

(ИТАР—ТАСС).

ЮТӘЛДӘН АРЫНУ

1. 60 грамм борычны 250 грамм ак винода кайнатып алырга. Бу массаны сыгып алып көненә өч тапкыр кайнар килеш эчәргә кирәк. Өстәмә рәвешендә бер зур суганны кыргычтан үткәреп, каз мае белән болгатырга. кичен, йоклар алдыннан шуның белән күкрәкне уарга.

2. Балалар бума ютәлдән интексә, сарымсакны ваклап сөттә кайнатырга да көненә берничә мәртәбә эчәргә.

3. Ютәл озакка китсә, күкрәкне коры чүпрәк белән корытырга да дуңгыз мае яки сары май белән сеңеп беткәнче уарга.

Кәкре Атау авылында яшәүче Нурия Летфулла кызы Яруллинага 65 яшь тула. Кадерле әниебез! Сине чын күңелдән туган көнең белән котлыйбыз. Күз карасы кебек багып үстергән балаларыңның игелеген күреп саусәламәт, кайгы-хәсрәтсез яшә.

Әни бит ул—өйнең яме,
Ә тормышта—олы бер терәк.
Озак яшә, сәламәт бул,
Син бит, әни, безгә бик кирәк.

БАЛАЛАРЫ, ОНЫКЛАРЫ.

БЕЛДЕРҮЛӘР

«МАКВИС» кече предприятиесе төрле модификациядәге «УАЗ» машиналары сата. Бәяләр базар бәяләреннән түбән. Түләү кулдагы акчалар белән һәм кулдан түләмичә үткәрелә. Түбәндәге телефон буенча хәбәрләшегез: Ульяновск—34—07—37. Көндезге 10 нан көндезге 15 сәгатькә кадәр шалтыратыгыз.

x x x

«Октябрьскагропромснаб» МТСы базасына даими эшкә мастер-төзүче (айлык хезмәт хакы 5000 сум); кочегарлар (4400 сум) кирәк.
Безнең адрес: Норлат шәһәре, Лесосклад урамы, 1. Телефон: 2—29—92.

Октябрь хуҗалыкара төзелеш оешмасы коллективы ире

ХАФИЗ СӘЛИХҖАН улының

фаҗигале төстә үлүе сәбәпле оешма эшчесе Рушания Минтаһир кызы Мифтиханованың авыр хәсрәтен уртаклаша.

Сез беләсезме әле?

ӘЙЛӘНӘ ТОРГАН ЙОРТ

Австралиянең Сидней шәһәрендә ике тәүлек дигәндә үз күчәрендә тулы әйләнеш ясый торган 30 катлы йорт төзергә ниятлиләр. Бу корылма һәр көнне 180 градуска борылып, төнлә үзенең вертикаль терәгенә таянып «йокыга» китәчәк икән. Бу йортның һәр тәрәзәсеннән шәһәрнең һәм океан киңлекләренең гаҗәеп матур манзарасын күзәтеп булачак.

МӨХӘРРИР В. В. ИСХАКОВ.

Учредительләр: редакциянең иҗат коллективы һәм халык депутатларының Октябрь район Советы.

Редакциянең адресы: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. Телефоннар: мөхәррир 2—12—14, 2—22—81; мөхәррир урынбасары һәм советлар тормышы бүлеге 2—10—44; рус теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—14—16; чуваш теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—15—63; авыл хуҗалыгы бүлеге 2—10—44; яңалыклар һәм промышленность бүлеге 2—22—51; җаваплы секретарь, хатлар, массалар белән эшләү, радиотапшырулар бүлеге, бухгалтерия һәм реклама бүлеге 2—18—67; фотокорреспондент 2—15—63.

Газетаның басылу сыйфаты турында типография директорына түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә: 2-10-54.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Нина ТОЛМАЧЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА.

Күләме—1 басма табак.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә. Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе. Тираж 3751. Заказ 110.